Республика Татарстан
Исполнительный комитет
Мунайкинского сельского поселения
Менделеевского муниципального района
423652 д.Мунайка ,ул. Строителей, д.12
Тел.(85549)3-58-09

Татарстан Республикасы
Менделеев муниципаль районы Монай
авыл башкарма комитеты
423652 Монай авылы, Тезучелэр ур.
12 нче йорт
Тел.(85549)3-58-09

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

16.12.2024 ел №57

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районының
Монай авыл җирлеге муниципаль
берәмлегенең җирдән файдалану һәм
төзелеш кагыйдәләре проекты буенча
ачык тыңлаулар үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 28 статьясы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 46 статьясы, Монай авыл җирлеге Уставы, ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә ярашлы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елның 17 гыйнваре 17.30 сәг. Татарстан Республикасы, Менделеевск районы, Монай авылы, Төзүчеләр урамы, 12 йорт адресы буенча урнашкан Монай авыл мәдәният йорты бинасының актлар залында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Монай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар уздырырга.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча ачык тыңлауларны оештыру һәм уздыру өчен түбәндәге составта комиссия төзергә:
Кириллов Р.М. – Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге башлыгы;
Әбүбәкеров И.Ш.- Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге Советы рәисен урынбасары;
Садриева З.М. – Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге депутаты;
3. 2024 елның 16 декабреннән 2025 елның 17 гыйнварына кадәр «Монай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча материаллар экспозициясен Татарстан Республикасы, Менделеевск районы, Монай авылы,Төзүчеләр урамы, 12 йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында оештырырга.
4. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр түбәндәге адрес буенча кабул ителә (җибәрелә): 423652, Татарстан Республикасы, Менделеевск районы, Монай авылы, Ленин урамы, 54 йорт (Менделеевск муниципаль районының Монай авыл җирлеге башлыгы исеменә).
5. Әлеге карарны «Интернет» челтәрендәге Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendsleevsk.tatar.ru . «Монай авыл җирлеге» бүлегендә һәм

Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны үземдә калдырам.

Менделеевск муниципаль районы
Монай авыл җирлеге башлыгы Р.М.Кириллов